| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ**

07.02.2022 г. Казань № 8-од

Татарстан Республикасында «Эхо веков
в истории семьи – Тарихта без эзлебез»
шәҗәрә фестивале турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале (алга таба – Фестиваль) турында нигезләмәне расларга.

2. Архив документларын фәнни файдалану һәм халыкара элемтәләр бүлегенә:

- эшче төркем төзергә;
- җаваплы башкаручыларны билгеләргә;
- Фестивальне оештыру һәм үткәрүнең чаралар планын («юл картасын») әзерләргә;
- Фестивальне расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга һәм үткәрергә.

3. Финанс-икътисад бүлегенә Фестивальдә җиңүчеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар хисабына акча түләүне гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында» 2021 елның 3 февралендәге 23-од номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2022 елның 7 февралендә 8-од номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» ел саен уздырыла торган шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» ел саен уздырыла торган шәҗәрә фестиваленең (алга таба – Фестиваль) максатларын һәм бурычларын, аны үткәрү тәртибен, эчтәлеген, катнашучыларына карата таләпләрне билгели.

1.2. Фестиваль Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган 2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерүнең дәүләт программасына кушымтаның 1.4.7 пункты нигезендә үткәрелә.

1.3. Фестивальне оештыручылар – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе.

2. Максат һәм бурычлар

2.1. Фестивальне үткәрүнең төп максатлары һәм бурычлары:

- буыннар алмашын саклап калу, милли гореф-гадәтләрнең һәм эстетик идеалларның бергәлеге нигезендә гаилә һәм гаилә-туганлык элемтәләрен ныгыту;

- үз нәселе, халкы, туган як тарихын өйрәнү;

- Татарстан Республикасы халыкларының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен торгызу;

- гаилә иҗаты традицияләрен яклау һәм үстерү, яшь буынга эстетик, әхлакый һәм рухи тәрбия бирүдә аның ролен көчәйтү.

3. Фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Фестивальне үткәрү тәртибе, сроклары, шартлары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) урнаштырыла.

3.2. Фестивальдә катнашуга гариза биргән Фестивальдә катнашучы оештыру комитетына бирелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы була.

3.3. Фестиваль 3 этапта уздырыла: муниципаль, зона һәм республика этаплары, аларда катнашучыларны сайлап алу була.

3.4. Фестивальне әзерләү һәм уздыру өчен оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3.5. Оештыру комитеты:

- Фестивальне үткәрү регламентын билгели;
- Фестивальне турыдан-туры үткәрүне тәэмин итә;
- Фестивальнең жюри карарын беркетмә белән рәсмиләштерә;
- Фестивальне әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияләүне гамәлгә ашыра;
- оештыру мәсьәләләрен хәл итә;
- әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Оператив мәсьәләләрне хәл итү өчен оештыру комитеты эшче төркемнәр төзергә хокуклы.

3.6. Фестивальдәге жюри (алга таба – жюри):

- Фестивальдә катнашучылар тарафыннан биремнәрне һәм башка төр сынауларны үтәү нәтиҗәләрен тикшерә һәм бәяли;
- Фестиваль җиңүчеләре, призерлары кандидатураларын билгели.

3.7. Жюри карары утырышта катнашучы әгъзаларының балл билгеләре нигезендә кабул ителә һәм утырышта катнашучы жюри әгъзалары һәм рәис тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Баллар саны тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

## 4. Фестивальнең муниципаль һәм зона этапларын үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

4.1. Фестиваль 3 этапта үткәрелә: муниципаль, зона, республика.

4.2. 1 этап – муниципаль этап Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә муниципаль хокукый актларда билгеләнә торган срокларда 15 февральдән алып 30 мартка кадәр үткәрелә.

Фестивальнең муниципаль этабы муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты вәкилләре катнашында үткәрелә.

Фестивальнең муниципаль этабында беренче урынны алган катнашучылар Фестивальнең зона этабына җибәрелә.

4.3. 2 этап – зона этабы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә зона этабы уза торган муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре белән алдан килештерелгән график буенча 5 апрельдән алып 13 апрельгә кадәр үткәрелә.

Зона этабында катнашу өчен шулай ук, Фестиваль турында нигезләмәдә каралганча, муниципаль этап үткәрелмәгән муниципаль районнардан гаилә коллективлары да чакырыла.

Фестивальнең зона этабы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә 6 зонага бүленгән

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә оештырыла һәм үткәрелә:

1 зона. Чирмешән авылы, Чирмешән муниципаль районы (Лениногорск, Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Мөслим, Сарман, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары);

2 зона. Чаллы шәһәре (Актаныш, Әгерҗе, Зәй, Алабуга, Минзәлә, Менделеевск, Түбән Кама, Тукай муниципаль районнары һәм Чаллы шәһәре);

3 зона. Яңа Чишмә авылы, Яңа Чишмә муниципаль районы (Аксубай, Алексеевск, Чистай, Әлки, Лаеш, Нурлат, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Спас, Чистай муниципаль районнары);

4 зона. Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы, Саба муниципаль районы (Арча, Әтнә, Балтач, Биектау, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Саба, Теләче муниципаль районнары);

5 зона. Зеленодольск шәһәре, Зеленодольск муниципаль районы (Тәтеш, Апас, Буа, Югары Ослан, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Чүпрәле муниципаль районнары);

6 зона. Казан шәһәре – Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары.

Фестивальне үткәрү зоналары (муниципаль берәмлекләр) ел саен күчә торган график буенча үзгәртеләчәк.

4.4. Фестивальнең зона этабын үткәрү тәртибе.

4.4.1. Фестивальнең зона этабында әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктында күрсәтелгән зоналарга кергән муниципаль берәмлектән муниципаль этапны узган, милләте һәм дине нинди булуга бәйсез рәвештә гаиләнең берничә буынын берләштергән, яшь чиге билгеләнмәгән бер гаилә коллективы (гаилә-туганнар төркеме) (кимендә өч кеше, катнашучыларның максималь саны чикләнми) катнаша.

4.4.2. Фестивальнең зона этабы программасы 2 блокны үз эченә ала, алар жюри әгъзалары тарафыннан расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралганча) бәяләнә:

1) әзерләнгән милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (камыр ризыгы, традицион һәм махсус ризыклар), регламент 3 минуттан озак түгел;

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары конкурсы – шәҗәрә презентациясе белән бергә матур концерт номерын үз эченә алган команданың визит карточкасы. Номерның куелу рәвеше ирекле: бию, җыр, театральләштерелгән тамаша һ.б. Гаилә милли костюмы да күрсәтелергә мөмкин. Регламент 7 минуттан озак түгел.

Регламент бер командага 10 минуттан озак түгел.

4.4.3. Гаиләнең генеалогик агачы (шәҗәрә) гаилә династияләрен аңлатудан, ядкәрләр һәм коллекцияләр турындагы материаллардан, гаилә тормышындагы кызыклы фактлардан (гаилә риваятьләре) гыйбарәт булырга һәм, альбом, стенд, панно, баннер-коллаж һ.б. рәвешендә бизәлгән булып, тәкъдим ителгән шәҗәрәнең текст нигезләвен дә үз эченә алырга тиеш.

4.4.4. Массакүләм мәгълүмат чараларында Фестивальне яктырту оештырыла, район һәм шәһәр басма матбугатында тәкъдим ителгән шәҗәрәләр бастырыла.

4.5. Фестивальнең зона этабында беренче урынны алган катнашучылар Фестивальнең республика этабына җибәрелә.

## 5. Республика этабын үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

5.1. 3 этап – республика этабы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан 15 апрельдән алып 15 майга кадәр (алга таба – республика этабы) үткәрелә.

Республика этабына йомгак 15 майда ясала.

5.2. Фестивальнең республика этабын үткәрү тәртибе.

5.2.1. Фестивальнең республика этабы программасы 2 блокны үз эченә ала, алар жюри әгъзалары тарафыннан расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган) бәяләнә:

1) Әзерләнгән милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (камыр ризыгы, традицион һәм махсус ризыклар). Регламент 3 минуттан озак түгел;

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары конкурсы – шәҗәрә презентациясе белән бергә матур концерт номерын үз эченә алган команданың визит карточкасы. Номерның куелу рәвеше ирекле: бию, җыр, театральләштерелгән тамаша һ. б. Гаилә милли костюмы да күрсәтелергә мөмкин. Регламент 7 минуттан озак түгел.

Бер командага регламент 10 минуттан озак түгел.

5.2.2. Гаиләнең генеалогик агачы (шәҗәрә) гаилә династияләрен аңлатудан, ядкәрләр һәм коллекцияләр турындагы материаллардан, гаилә тормышындагы кызыклы фактлардан (гаилә риваятьләре) гыйбарәт булырга һәм, альбом, стенд, панно, баннер-коллаж һ.б. рәвешендә бизәлгән булып, тәкъдим ителгән шәҗәрәнең текст нигезләвен дә үз эченә алырга тиеш.

5.2.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында Фестивальне яктырту оештырыла.

## 6. Җиңүчеләрне билгеләү, нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе

6.1. Зона этабы призерлары (1, 2, 3 урыннар) жюри тарафыннан беренче һәм икенче блокларның баллары суммасы буенча билгеләнә, дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән түбәндәгечә бүләкләнә:

13 000 (унөч мең) сум – I урын өчен

10 000 (ун мең) сум – II урын өчен

8 000 (сигез мең) сум – III урын өчен.

6.2. Республика этабы призерлары (1, 2, 3 урыннар) жюри тарафыннан беренче һәм икенче блокларның баллары суммасы буенча билгеләнә, дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән түбәндәгечә бүләкләнә:

150 000 (йөз илле мең) сум – I урын өчен

130 000 (йөз утыз мең) сум – II урын өчен

100 000 (йөз мең) сум – III урын өчен.

## 7. Жюри

7.1. Гаилә коллективлары чыгышларын бәяләү максатыннан жюри составы төзелә.

7.2. Жюриның персональ составына Татарстан Республикасы Дәүләт архивы боерыгы белән республика башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ вәкилләреннән, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләреннән гыйбарәт рәис, рәис урынбасары җитәкчелегендәге 15 кеше раслана.

7.3. Жюри эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда, вазыйфалар аның урынбасарына йөкләнә. Жюриның экспертларны өстәмә җәлеп итү хокукы була. Фестивальнең гаилә коллективлары чыгышларын бәяләү нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булган затлар жюри әгъзалары була алмый.

7.4. Жюри эше аның утырышында башкарыла. Утырыш, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

7.5. Жюри карары утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм рәислек итүче кул куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышларның саны тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

## 8. Финанслау

8.1. Фестивальне финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» ел саен уздырыла торган шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

Милли һәм гаилә ризыкларын бәяләү критерийлары

| № | **Ризыкны бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| 1. | Тәкъдим итү (савыт-саба, бизәү өчен атрибутлар) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 2. | Әзерләүнең техник катлаулыгы | 0 алып 10 кадәр балл |
| 3. | Тәме | 0 алып 10 кадәр балл |
| 4. | Эстетик башкарылышы (тышкы кыяфәте, консистенциясе, төсе) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 5. | Милли декор элементларын куллану | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |
| 6. | Вакытны чикләү буенча регламентның үтәлүе | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |

Командаларның визит карточкаларын бәяләү критерийлары

| № | **Критерийлар** | **Баллар** |
|---|---|---|
| | **Шәҗәрәне презентацияләү** | |
| 1. | Җыр башкару (башкару сыйфаты, вокалга осталык, башкару катлаулылыгы) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 2. | Бию номеры (номерның катлаулылыгы, башкару техникасы, биючеләр саны) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 3. | Барлык гаилә әгъзаларының катнашуы | юк – 0 балл;<br>әйе - 5 балл |
| 4. | Аудиовизуаль мөмкинлекләр (аудиовизуаль рәтнең техник характеристикалары: сурәтнең сыйфаты, тавышның чисталыгы һ. б.) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 5. | Сәнгать номеры (театральләштерү, пантомима һ. б.) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 6. | Номерның оригинальлеге (гадәти булмаган алым) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 7. | Акробатик элементлар башкару | 0 алып 10 кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| | (комбинацияләрнең катлаулылыгы, башкару техникасы) | балл |
| 8. | Музыка уен коралларын куллану | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |
| 9. | Техник чаралар яки декорацияләр куллану (дизайн, милли элементлар) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 10. | Фотодокументлар булу | юк – 0 балл;<br>бар - 5 балл |
| 11. | Шәҗәрә төзүче турында мәгълүмат булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 12. | Генеалогик агач (шәҗәрә) төзү (туу, вафат булу датасы, кайсы катламга каравы, вазыйфасы, исеме турында язмалар, гаилә риваятьләре һ.б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 13. | Исемнәре һәм гамәлләре торак пунктларның, җирлекләрнең һәм башка объектларның атамаларына нигез итеп алынган кешеләр турында кыскача белешмәләрнең булуы | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 14. | Кешеләр, вакыйгаларның замандашлары белән бәйле булган тарихи вакыйгаларның кыскача тасвирламасы булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 15. | Шәҗәрәне җентекләп күрсәтү һәм аның тарихи (архив) белешмәләргә туры килүе | 0 алып 10 кадәр балл |
| 16. | Шәҗәрәне төзегәндә кулланыла торган архив һәм документаль чыганакларның күләме (гаилә, муниципаль һәм дәүләт архивлары документлары) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 17. | Генеалогик туганлык терминнарын (ягъни субъектларның туганлык дәрәҗәсен билгели торган терминнар) дөрес куллану | 0 алып 10 кадәр балл |
| 18. | Шәҗәрәнең сәнгатьчә бизәлеше (оригинальлек, дизайн, иҗади якын килү һ. б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 19. | Артистлык (риторика, сәхнә осталыгы, импровизация күнекмәләре һ. б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 20. | Вакытны чикләү буенча регламентның үтәлүе | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |
| | **Гаилә милли киемен күрсәтү** | |
| 1. | Гаилә костюмы булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 2. | Этник мотивлар булу | юк – 0 балл;<br>бар – 10 балл |
| 3. | Оригинальлек (образ гармониясе һәм күркәмлеге, костюмның сыйфаты, чигүле булу) | 0 алып 10 кадәр балл |